ГЛАВА СОБОЛЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Береговая, д.30, с. Соболевское,
422595

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
СОБОЛЕВСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яр ур., 30 нчы йорт, Соболевский авылы,
422595

Тел.: (84379) 35-7-22, факс: (84379) 35-7-22.

11.12.2024 № 1

На №______________от________________

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылында 2025 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә ризамы? " - Карамышиха авылы торак пункты чикләрендә Үзәк урам буенча гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, дигән сорау буенча 2024 елның 7 декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.
Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 33 катнашучысы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 22 кеше кертелгән.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 22 катнашучы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авылы җирлегенең Карамышиха авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.
2. Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (ташламага ия булучылар категориясеннән тыш) Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылында 2025 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә ризамы? " -

Карамышиха авылы торак пункты чикләрендә Үзәк урам буенча гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, дигән сорау буенча караны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылындагы гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Соболевский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: ___________________ О.Н.Майорова